**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлеге составына керүче Зәй тимер юл станциясе поселогы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 12 апреле, № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында " 29.11.2023 ел, № 1532 Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары белән 22.11. 2013 № 909 (29.11.2023 no 1532 редакциясендә), Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлегенең Зәй тимер юл станциясе поселогы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлегенең Зәй тимер юл станциясе поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Яңа Александровка авыл җирлегенең Зәй тимер юл станциясе поселогында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Зәй тимер юл станциясе поселогында яшәүчеләргә су бирү өчен тирәнлек насосы һәм өстәмә җиһазлар сатып алу)

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**Яңа Александровка авыл җирлеге башлыгы Е. Г. Гыйрфанова**